*Сугыш чоры баласы.*



**Нәҗмиева Надия** Сәлих кызы

Туган елы: **1930 ел**

**Туган урыны: Күәм авылы**.

Белеме : 7 класс

Надия 1930 нчы елның 10 июнендә Гатауллиннар гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Гаиләдә 6 бала булып тәрбияләнәләр. Надия апа җиде еллык мәктәпне тәмамлый. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа нибары 11 яшь була. Әтиләре 1941 елда сугышка алына, ә 1943 елда аның Смоленск өлкәсеннән үле хәбәре килә. Гаиләдә 6 бала әтисез, ятим кала. Дәһшәтле еллар афәтен һәр гаилә кичерде. Күп аналар тол калды, улларын һәм кызларын югалтты. Сугыш тирән яра калдырды, йөрәкләргә әрнү салды. Таза ир-атларны сугышка алдылар, авылда эшләрдәй кеше калмады. Бөтен эш бала-чагага, карт-корыга калды. Надия апа гаиләсе дә ачлы-туклы яшәгән, ә бит 6 баланы туендырасы бар. Зурраклары белән басудан коелып калган бөртекләрне җыйганнар.Басуда көзен җыелмыйча, өшеп калган бәрәңгеләрне дә чүпләгәннәр. Көз көннәрендә басуда көлтәләр бәйләгәннәр. Ашар өчен балалар болыннан капчыклап ат кузгалагы җыя торган булганнар. Әниләре шул капчыкларны идән астына төшереп элеп куя торган булган.Ашарга беткән саен аннан аш пешергән.

- Тәлинкәләр, үзебез ямь-яшел була идек, ярый әле сөтле сыерыбыз булды. Мари урманнарына агач кисәргә, Алат заводына өшегән бәрәңгеләрне җәяү чана белән алып бара идек. Сугыш чорында нинди авыр эш туры килде барысын да эшләдек. Мичкә ягарга утын юк иде, утынын да кистек, печәнен дә әзерләдек, - дип искә ала ак яулык әби. Без тормышыбыз ач көе, аяк чабаталары тузган килеш, кайчагында яланаяк сукасын сукаладык, вакыт белән исәпләшмичә урагын урдык, ашлыгын фронтка озаттык. Җитәр-җитмәс көчебез белән Җиңүне, сугышның бетүен якынайту өчен кулдан килгәннең бөтенесен дә эшләргә тырыштык. 1952 елны Нәҗмиев Әкрамгә кияүгә чыга. Алар бергәләп 5 бала тәрбияләп үстерәләр.Бүгенге көндә Надия апа 84 нче яше белән бара.

**Фазлыев Камил Закирҗан улы**




**Туган елы**:  20нче февраль, 1932 ел
**Туган җире**: Әтнә районы, Күәм авылы.
**Әти-әнисе**: Закирҗан, Әсмабикә.
**Белеме:** 4 еллык башлангыч мәктәп.


Фазлыев Камил Закирҗан улы 1932 елның 20нче февралендә Әтнә районы Күәм авылында дөньяга килә.  1935елда,  Камил абыйга 3 яшь булганда,әнисе үлеп китә. Камил абый әнисе турында бернәрсә дә белми. Әтисе икенче хатынга өйләнә. Ләкин аңа үги әни тәрбиясендә озак торырга насыйп булмый. Үги әни дә үлеп китә. 1942 елда әтисе дә үлә. Ятим калган малайны, ике сеңлесе белән Күлле Кимедәге балалар йортына җибәрәләр. Шунда ул дүртьеллык башлангыч мәктәпне тәмамлый.

12 яшендә малайны 20ләп яшьтәше белән Казанга ФЗУ га озаталар. Камил абый анда “Татваленки” киез итек фабикасында эшли. Бу вакытта илдә
дәһшәтле сугыш бара. ”Казанга ике ат белән 20ләп бала көн ярым бардык.Кабан күле буенда урнашкан бер иске бинада 50 бала тордык. Ипи урынына карабодай коймагы, кәбестә шулпасы ашаттылар.Ул чорларда бик газап чиктек. Өскә кияргә киемнәр юк, ашарга такы-токы гына. Җитмәсә бергә яшәүче  кайбер урыс балалары безне кыерсытты. Сугыштан ремонтларга дип эшелон белән тузган киез итекләр кайта иде. Аларны бушата идек.Фабрикада эшбик авыр һәм пычрак иде. Киез итек басу станогында да эшләдем “, - дип искә ала бу турыда Камил абый.

Бөек Җиңүне ул шушы фабрикада каршы ала. Сугыш беткән көнне шәһәрдә демонстрация була.Камил абый һәм фабрикада эшләүче иптәшләре өчен чын бәйрәм була ул көнне. Аларны сугыш бетү хөрмәтенә туйганчы ашаталар.Кабан күлендә су коеналар, ул көнне уен-көлке, җыр-бию тынып тормый. Шушы көн аның өчен иң истәлекле, иң күңелле вакыйга булып исендә кала.

Сугыштан соң Камил абый илдә барган индустриаль төзелешләрдә катнаша.” 2 ел - Свердловскийда,1 ел – Кемеровода сал агызу, кирпеч сугу хезмәтләрен башкара. Монголиядәи4 елга якын хәрби бурычын үти.
Туган авылына кайтып шул ук авыл кызы Әнисә апа белән тормыш корып җибәрә.Икесе бергә 4 бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта ул улы Илфар һәм аның гаиләсе тәрбиясендә яши.

Сугыш чорындагы хезмәтләре өчен аңа “Тыл ветераны” исеме бирәләр, ***1978 елда ВДНХның “Алтын медал”е, 1981 елда ВДНХның “Бронза медал”е,*** Бөек Җиңүнең 50, 55, 60, 65 еллыгына медальләре белән бүләкләнә. Үзенең шушы уңышларының асылында тырышлык, үз эшенә бирелгәнлек, авырлыктан курыкмау, иманыңны югалтмау кебек сыйфатлар ята, дип саный Камил абый.



**Файзрахманова Фәүзия Исхак** кызы

Туган елы: 1924 ел 3 май

Туган авылы: Күәм

Белеме: 7 класс

**Файзрахманова Фәүзия Исхак** кызының да үсмер чагы сугыш елларына туры килгән. Бу авыр елларның ачысын да, төчесен дә татырга туры килгән аңа, "нуҗа шулпасын" да байтак чөмергән ул.

Мин 1924 елның матур май башында Күәм авылында дөньяга килгәнмен. Гаиләдә 8 бала, шуларның иң олысы мин идем. Әнигә балаларны карашу минем өстә иде. Ләкин өч туганым вафат булдылар, бәлки яхшы тәрбия дә булмагандыр инде ул чакларда. Сугыш башланганчы гаиләбез белән Тулага күченеп киттек. Ләкин анда озак яши алмадык, чөнки сугыш башланды. Яңадан туган авылыбыз Күәмгә әйләнеп кайттык.Сугыш башланган вакытта миңа нибары 17 яшь иде. Егетләрне, әтиләрне военкоматка комиссиягә йөртә башладылар. Әтиебез сугышка яраксыз булды, чөнки аның тәннәрендә яра эзләре бетмәгән була. Авылда ир-егетләр калмаганлыктан басуларда алар эшләгән эшне башкарырга туры килде. Фронт өчен дип көнне-төнгә ялгап эшләдек. Колхоз терлекләрен, дуңгызларны карадым, урак урырга, ындыр табагында да эшләргә туры килде, - ди Фәүзия апа. Ләкин ул зарланмаган, иңнәренә төшкән авыр йөкне җигелеп тарткан. Җирне сөрергә, эшкәртергә дә туры килгән аңа. Әниләре белән көлтә өю, печән чабу кебек эшләрне дә башкарганнар.Ә бигрәк тә истә калганы, Мари урманнарына җәяу барып, утын кисү. Агачларны елга аша сал итеп агызу. Ачлы –туклы урман эчендә баракларда яшәгәннәр. Өстә юньле кием юк иде, аякта чабата. Ул тузып бетә, ертыла. Эшләгән тулы хезмәт көненә 1 кг ипи бирелә иде, ләкин норманы үтәсәң генә шул. Көз көннәрендә басуда бәрәңгеләр өелеп кала иде. Карлы, бозлы яңгыр астында да казыдык, өшегән бәрәңгеләрне капчыкларга тутырып чана белән Алат спирт заводына тапшырдык. Көек, Шимбер юллары аша бер төркем кыз: Гөлбәрия, Надия һәм башкалар белән төнлә юлга кузгала идек. Ул өшегән бәрәңгедән яралыларны дәвалау өчен спирт ясаганнар дыр,- инде. Ә атлар юк, чөнки яхшы атларны сугышка алып бетерделәр.Ә хәлсез атлар ерак юлга чыга алмады. Озын кыш төннәрендә кич утырып сугышчыларга йон оекбашлар бәйли идек. Көнозын эшли идек,

кайтып такы-токы белән чәй эчкәч арулар беткән кебек була иде, без кичке уенга чыгып китә идек. Моны гаеплəп булмый, без дә бит яшьләр идек.Арыганлык бөтенләй онытыла. Җырлар, биюләр, уеннар... Ә иң истә калганы 1944 - 45 еллар – ди Фәүзия апа, торф чыгару. Безне Әтнәдән 15 кызны Мәскәү өлкәсенә торф чыгарырга җибәрделәр. Дусым авылыннан-өчәү, Җегелдедән- икәү, Әтнәдән-өчәү һәм башка авыллардан. Күәмнән Гатауллина Әминә, Җәләева Фәймә идек. Анда баракларда тордык. Хезмәт хакы түләнмәде, ашаталар иде үзе. Яралы солдатларның киемнәрен дә юдык. Әсирлеккә төшкән немец солдатлары белән бергә эшләдек.Торфны кәрзингә тутырабыз, алар аны ташый иделәр.Безгә паек белән беррәттән тәмәке дә бирелә иде, ә без аны немец солдатларыннан шикәргә алыштырып ала идек. Җиңүне без кызлар белән Мәскәү өлкәсендә каршыладык. Ә өйгә кайтканда безгә бик күп бүләкләр, чүпрәк-чапраклар бирделәр. Әнием 49 яшендә вафат булды, 2 яшьлек туганымны да тәрбияләү минем өскә калды.Аңа карамастан басуда көлтәсен дә бәйләдем.Атлы машина алдан урып бара, ә без җырлый-җырлый көлтәлибез. Фермасында да эшләдем. Тырыш хезмәте өчен “Тыл ветераны” һәм “Хезмәт ветераны” исеме бирелгән. 1953 елда Күәм авылы егете Равилгә кияүгә чыктым. Өч бала тәрбияләп үстердем. Иптәшем белән бергә 32 ел бәхетле гомер кичердек, ләкин ике улымны югалттым.Бүгенге көндә 39 ел бергә гомер кичергән киленем һәм оныкларым белән яшим. Киленем Назира үзем кебек тырыш, 36 ел фермада сыер сауды. Инде менә яшь килен белән дә җиде ел торам. Ул да олы киленемә бик ошаган, уңган. Җиде онык, 13 оныкчыгым бар. Алар өчен куанып яшим, - ди Фәүзия апа күз яшьләрен сөртә-сөртә. Сугыш бетә, яралар төзәлә, ләкин күңелләрдә мәңге эз кала, хәтер кала. Менә бит нинди авыр тормыш кичергән сугыш чоры баласы.



***Сугыш чоры баласы***

**Шәрипова Гөлсинә Шәйхетдин кызы**

**Туган елы:**1932 елның 5 июнендә

**Туган ягы**: Апас районы Күккүз авылында туа.

Җиде яшенә кадәр әти-әниле бәхетле бала-чагы уза. Әниләре 1939 елда бала тапканда вафат була. Әнисез калган Гөлсинә апа өстенә авырлык өстенә авырлык килеп тора. 1941 елда әтиләренә сугышка китәргә повестка килә. Балалар елый-елый әтиләрен сугышка озатканнар. Гөлсинә апаның әтисе ” Борчылмагыз, мин кайтырмын” – диеп балаларын соңгы тапкыр кочаклап, җырлый-җырлый сугышка киткән. Ләкин 1942 елда сугыш кырында бик күп батырлыклар эшләп үлеп кала.

Әтиемне сугыш алып китте

Мин үскәнне дә күрмәде.

Син киттең дә юкка чыктың

Ә мин әти-әни назы күрмәдем.

Гаиләдә 3 ятим бала кала. Фашизмның кансызлыгы тугыз яшьлек баланың һәр күзәнәге аша узган дияргә мөмкин. Шулай да, бүгенге көндә сиксән икенче яше белән баручы әби күңел көрлеген саклап калган.

Гөлсинә апаны һәм балаларны туганнары Апас районы Дәвеш детдомына бирәләр Детдомда алар ачлы туклы яшиләр. Детдом балаларын да төрле эшләргә алып баралар, чөнки илдә эшче көчләр җитеп бетми. Басуда коелып калган башакларны җыярга туры килә аларга. Көз көннәрендә Зөя елгасы аша урманга чыбык -чабык җыярга чыкканнар.Детдом яңа булганлыктан, әле дәүләт тарафыннан эшләнеп тә бетмәгән була, ягарга утын булмаган.Күктә очкан самолетларны күреп балалар бик каты курыкканнар, дошман бомба ташламаса ярар иде,- дип. Детдом Гөлсинә апаны Куйбышев районындагы педучилищега укырга җибәрә. Анда ул 4 ел белем ала.Тәкәнеш районы Түбән Арбаш авылына тәрбияче итеп билгеләнелә. Анда аны балалар *“курчак апа”* дип кенә йөрткәннәр, чөнки ул бик матур, чибәр була. Аннан соң Гөлсинә апаны, үзе дә детдом баласы булаларк, Минзәлә детдомына эшкә җибәрләр. Детдом баласы детдом кагыйдәләрен белә. Анда ул 2 ел эшли. Детдомда эшләгән чорда бик күп куркыныч хәлләргә юлыга. Ул чорда караклар бик күп була. Бервакыт детдомга төнлә белән караклар керә.Тәрбиячеләр көч хәл белән качып калалар. Ләкин Гөлсинә апа зарланмаган сугыш афәтеннән ятим

калган балаларга әти-әни тәрбиясен дә, назын да биргән. Абыйсы армия сафларыннан хезмәт итеп кайткач,  аны үзе яшәгән туган якларына алып китә. Ранога эш сорап баргач, рано мөдире  аны Әтнә районы  Төрекләр башлангыч мәктәбенә билгели. Мәктәптә 2 ел балаларга белем бирә.Аннан соң Күәм авылына 5-6 сыйныфларга рус теле укытучысы итеп билгелиләр. Берничә ел укыткач, башлангыч сыйныфка күчә.Ә анда башлангыч сыйныф укытучысы булып озак еллар хезмәт итә. 1960 нчы елда Күәмдә укытучы булып эшләгән  егеткә кияүгә чыга. Шамил абый белән бергә 44 ел бәхетле гомер кичерәләр 5 бала тәрбияләп үстерәләр. 1954-1987 елларда Күәм мәктәбендә балаларга белем һәм тәрбия бирүдә үзенең бик тырыш хезмәтен куя. Бүгенге көндә ак яулыклы әби сиксән икенче яше белән бара. Ул  Күәм авылында  төпчек улы белән яши.

Сугышта җиңү яулауда сугыш чоры балаларының өлеше зур булды. Сугыш чоры балалары да олы яшькә җиттеләр, алар ел саен кимеп баралар – хөрмәткә лаек булуларын, Җиңү көннәрендә һәм башка бәйрәмнәрдә урыннары һәрвакыт түрдә булуын күрәсе килә.

# **Сугыш чоры баласы**

Шафикова Халисә Мөхәммәтҗан кызы




Туган елы: 1927 ел, 4нче сентябрь

Туган җире: Әтнә районы, Олы Бәрәзә авылы

Әти-әнисе: Мөхәммәтҗан, Рауза- колхозчылар

Белеме: җиде классны укыган

Шафикова Халисә Мөхәммәтҗан кызы 1927 елның 4нче сентябрендә Әтнә районы Олы Бәрәзә авылында колхозчы семьясында туган. 1935 нче елда Олы Бәрәзә җидееллык мәктәбенә укырга кергән. “Мәктәптә тәнәфес вакытында тамак ялгап алырга мичкә тәгәрәткән бәрәңге, черек бәрәңге күмәче тыгып бара идек. Әни черегән бәрәңгеләрне җыеп, әрчеп, төеп, бәрәңге күмәче пешерә иде.Тәнәфес вакытында шуларны ашый идек . Ул елларда язарга дәфтәрләр дә бетте”, дип искә ала ул мәктәп еллары турында.

Сугыш башланганда Халисә апага 13 яшь була. Әтисе Мөхәммәтҗан абый 1941 елның сентябрендә сугышка китә.

1942 елда Халисә апай Олы Бәрәзә җидеелык мәктәбен тәмамлый. Кайбер сыйныфташлары Олы Әтнәгә 8нче класска укырга китә, ә ул укуын дәвам итми.Чөнки өйдә кечкенә туганнарын да карарга кирәк була. Халисә апа колхозда эшли башлый.

Дәһшәтле сугыш елларында атларга ашатырга печән җыя, ашлык сугуда эшли, көлтә бәйли, басуда борчак йолкый .Урман кисәргә дә бара. Бу турыда ул ” Өйдән балта-пычкылар тыгып бардык. Алар үтми , агач кисәргә көч җитми иде. Өйдән үзебез белән бар булган ризыкны алып бара идек. Бик

авыр булды, хәзер бик рәхәт. Ходай бүтән андый газапларны беркемгә дә күрсәтмәсен,"- дип искә алды.

Арчадан олы Бәрәзәгә чәчүлек орлык ташу - үзе бер моңсу хатирә. "Арчага җәяү бара идек, орлык алырга чират иде.Капчыкка 16 кг орлык үлчәп салып бирәләр. Икмәкне алгач, Арча астындагы Бирәзәгә кайтып йоклый идек. Икенче көнне җәяүләп кайтабыз. Аякта чабата, кайтып җиткәнче ул тишелеп бетә . Ашарга такы- токы гына, ачлы-туклы, хәлсезләнеп, көчкә кайтып җитә идек",- дип сөйләде Халисә апа бу турыда.

Сугышта канашучыларга да хәлләреннән килгәнчә ярдәм иткән алар. Әнисе белән бергәләп, кич утырып, җылы оекбашлар бәйләгәннәр.

Җиңү көнен сөенеп,зур өметләр белән каршы алган Халисә апа. 1946 елның көзендә сугыштан әтисе дә әйләнеп кайткан.

Сугыш елларындагы хезмәтләре өчен Халисә апага "Тыл ветераны" исеме бирелә, "Бөек Җиңүнең 50, 55, 60, 65 еллыгы" медальләре белән бүләклиләр.

Сугыштан соң Халисә апа Күәм авылына Шәрифулла исемле егеткә кияүгә чыга. Аның белән бергә 3 бала тәрбияләп үстерәләр. Хәзерге вакытта ул улы Ринат һәм аның гаиләсе тәрбиясендә яши.

**Шафикова Халисә Мөхәммәтҗан кызының бүләкләре.**

